# Афәрин, Лилия!

яки

## *Шагыйрь турында шагыйрь*

*Шигырь ике очракта – телебезнең матурлыгын, нәфислеген, гаҗәеп төсмерләргә ия аһәңен чагылдырганда, көтелмәгән чагыштыруларга бай һәм заманга аваздаш-актуаль булганда, һичбер вакыт әһәмиятен югалмый. Закир Рәмиев-Дәрдемәнднең шигырьләре шундый.*



Дәрдемәнд шигырьләрен кайчан гына кулыңа алып укысаң да, бу дөньяның фанилыгына, мәгыйшәтнең тавык чүпләп бетерә алмаслык ыгы-зыгысына шаккатып, яшәешнең мәгънәсе ни-нәрсәдә соң, дип эзләнә башлыйсың. «Кораб», «Бүзләрем маналмадым», «Гөрләгән сулар башында», «Видагъ», «Әгәр барсаң саба җил безнең илгә»... – шаһәсәрләр. Әле дә кешелекнең, милләтнең «югалмас һәм ятып калмас» юанычлары бар: «Табып ләззәт матур дөнья сүзеннән Гомерләрдер жилеп йөрдем эзеннән».

Әдипнең табышмак сыман бер-ике мәртәбә укуда гына аңлап-аңлатып бетереп булмый торган әсәрләре дә байтак. Әйтик, «Түгел лаек яманлык яхшыларга, Ярамасларга яхшылык ярамас». Ни әйтергә теләгән моның белән автор: уйлагыз, мәгъшукә меңнәр!

Һәр заманда Закир Рәмиевне аңлатып карарга омтылучылар булды. Болар, билгеле, беренче чиратта, тәрҗемәчеләр. Әлеге шаһәсәрләрне башка тел иясенә аңлатырга җыенасың икән, әлбәттә, иң әүвәл үзең яхшы аңлау кирәк. Гадәттә, шагыйрьне аңлатырга тырышу омтылышлары әдипнең юбилейларына туры килә. Дәрдемәндебезнең тууына 165 ел тулуны билгеләп үткән көннәрдә мондый омтылышны Чаллыда яшәп иҗат итүче шагыйрә, «Мәйдан» журналының шигърият бүлеген җитәкләүче Лилия Гыйбадуллина ясады. Иҗатташ дуслары, каләмдәшләре Булат Ибраһимов, Рүзәл Мөхәммәтшин, Йолдыз Миңнуллина, Гөлүсә Батталова, «Татарстан-Яңа гасыр» каналы алып баручысы Зөлфия Шәмсуарова, җырчы Илгиз Мөхетдинов, театр артисты Илдус Габдрахманов, музыкант Ильяс Фәрхуллин белән бергә Камал театрының кече залында, күптән түгел генә үзе язган «Дәрдемәнд» поэмасын нигез итеп алып, «Исте җилләр ил эченнән» дип исемләнгән шигъри-музыкаль кичә (режиссеры Нәфисә Исмәгыйлова) оештырды ул.

Дәрдемәнд шигырьләрен укучы иҗат әһелләренә яшүсмер малайлар, 2013 елгы яшьтиләр – Идел, Сәйдәш, Закирның да кушылуы ямь өстенә ямь бирде. Идел Мөхәммәтшин – Рүзәлнең улы. Сәйдәш Гарифҗанов – сәхнә тотып өлгергән, «Куркак батыр» спектаклендә уйнаган «Апуш» театр студиясе шәкерте. Закир – Чаллыдагы «Адымнар» гимназиясенең V сыйныф укучысы – Лилия Гыйбадуллинаның үз улы. Кечкенә Закирның адашы шигырьләрен укуы – үзе бер символик мәгънәгә ия. Беренчедән, бу хәл – баланы әдипнең исемен кушу Дәрдемәндне «үлеп» яратуны аңлатса, икенчедән, Аллаһны зекер итүчене белдергән әлеге тирән мәгънәле исемне, ни кызганыч, хәзер бик сирәк кушалар. Дәвамлы булсын иде бу башлангыч!

Кичәнең исемен күргә («Исте җилләр ил эченннән») уйга, күңелгә әлеге юлларның дәвамы килә: «Иртә-кич салдым колак, Җил-җиләсләрнең моңыннан Зәүкы әлхан алмадым». Бүген дә җил-җиләсләр исеп тора, көй ләззәте юк. Дәрдемәндне шәрехләү ансат түгел. Миңа калса, максатына ирешкән шагыйрә:

*Килер көннәр ырылдавы ишетелә,*
*Килер көннәр тыпырдавы ишетелә.*
*Җил-җиләснең гариб моңы өннәрендә,*
*Бар ымнарны ишет кенә, ишет кенә.*

Менә тагын З.Рәмиев шигырьләренә аваздаш юллар:

*Гомерләрдер... Ак кыл булып өзелгәнче*
*Акку таушы тетрәп тора һаваларда.*
*Тирәлекләр тибри-тибри шаулап тора,*
*Фани дөнья саркып тора яралардан.*
*Килерме яз? Килерме җәй гөлләр алып?*
*Чыдармы җир? Тынармы җил,*
*җанга кагып?*
*Чыдармы ил?*
*Сынармы ил каккан казык?..*
*Кемнәр килер? Тора дөнья уйга талып...*

Озын сүзнең кыскасы: бу кичә бик күркәм Дәрдемәнд тәфсире булды.

Гадәттә, мондый кичәләрдә милләтнең «каймагы» җыела. Каймак кына түгел шул. Ни кызганыч, иҗатташларының хезмәте, тәҗрибәсе турында сүз барганда «татарлык» һәм «тарлык» сүзләренең рифмалашуына да шаһит буласың. Төркем-төркем бүлгәләнгән каләм әһелләребез дә бу чирдән азат түгел.

**Рәшит МИНҺАҖ.**